БАВЛИНСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

08.11.2024 Баулы шәһәре №143

Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советының 2019 елның 27 мартындагы 103 номерлы «Өченче зат хокукларыннан азат булган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына биләүгә һәм (яисә) файдалануга бирү өчен билгеләнгән Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге милкендәге муниципаль мөлкәт Исемлеген раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Исемлекне актуальләштерүгә бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы карары нигезендә,Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы шәһәр Советының 2019 елның 27 мартындагы 103 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль милкендә булган, өченче затлар хокукыннан азат булган, аны кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга озак сроклы нигездә (шул исәптән аренда түләүенең ташламалы ставкалары буенча) биләүгә һәм (яисә) файдалануга бирү максатларында, шулай ук түләүле нигездә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары милкенә читләштерү максатларында, (Баулы шәһәр Советының 2019 елның 16 октябрендәге 116 номерлы, 2020 елның 28 августындагы 141 номерлы, 2020 елның 23 октябрендәге 13 номерлы, 2021 елның 7 апрелендәге 28 номерлы, 2023 елның 30 ноябрендәге 115 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) мөлкәт исемлегенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

11 пункт белән тулыландырырга:

| № п/п | Мөлкәт атамасы | Төп характеристикалар | Урнашкан урыны (адресы) | Баланс тотучы |
|---|---|---|---|---|
| 11. | Гараж | 818,6 кв.м 16:55:010201:1270 | Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Пушкин урамы, 26А йорт | Татарстан Республикасы, «Баулы муниципаль районы» |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | муниципаль берәмлеге |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) адресы буенча һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы шәһәр Советының икътисади үсеш, эшмәкәрлек, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләтергә.

Баулы шәһәр мэры,
Шәһәр Советы рәисе И.И. Гозәеров